| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**29.04.2026** Зеленодольск шәһәре **№1482**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 ноябрендәге «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибен раслау турында» 2461 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 05 декабрендәге 999 номерлы карары нигезендә норматив документларны туры китерү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 ноябрендәге «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибен раслау турында» 2461 номерлы карарына (2019 елның 28 декабрендәге 2587 номерлы, 2021 елның 2 февралендәге 141 номерлы 2021 елның 30 апрелендәге 1006 номерлы, 2023 елның 24 мартындагы 845 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районындагы Республика матди ярдәм үзәгенең 21 нче бүлеген» компенсация түләүләре өчен вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 декабрендәге 2461 номерлы карары белән расланган (2019 елның 28 декабрендәге 2587 номерлы, 2021 елның 2 февралендәге 141 номерлы 2021 елның 30 апрелендәге 1006 номерлы, 2023 елның 24 мартындагы 845 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) «Мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. Тәртипнең 2.1 пунктындагы «б» пунктчасында «алты ай» сүзләрен «унике ай» сүзләренә алмаштырырга;

2.2. Тәртипнең 2.6 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

2.3. Тәртипнең 2.7 пунктында:

тиешле килешләрдә «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен тиешле килешләрдә «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминләштерү фонды» сүзләренә алмаштырырга.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин